Татар тел белемендә XX йөзнең икенче яртысыннан башлап, лингвистиканың бер тармагы булган ономастика фәне, төрле телләр материалына нигезләнеп, гыйльми тикшеренүләр нәтиҗәсендә елдан-ел киңәя, тирәнәя бара. Шуның белән бергә ономастиканың табигый һәм кеше тарафыннан булдырылган географик берәмлек атамаларын өйрәнә торган тармагы – топонимика фәне киң үсеш ала. Дастаннарда тарих белән бәйле вакыйгалар сурәтләнгәндә, ялгызлык исемнәренә еш мөрәҗәгать ителә. Мәкаләдә татар халкының тарихи героик-эпик шигъри дастаны «Идегәй»нең поэтик топонимиясе тикшерелеп, аның әдәби-эстетик вазифасы һәм семантикасы ачыклана. Иҗтимагый-тарихи һәм әдәби-мәдәни кыйммәткә ия булган әсәрдә киң кулланылган Идел, Җаек, Казан атамаларының кыскача тарихы бирелә.

**Төп төшенчәләр:** татар теле, поэтик ономастика, поэтик топонимия, этимология, «Идегәй» дастаны, Идел, Җаек, Казан.

Тормыш-чынбарлыктан килеп кергән тарихи шәхес исемнәре, географик объект атамалары һәм автор тарафыннан уйлап табылган онимнарның әсәр ономастиконында тоткан урыны һәм үзара мөнәсәбәте проблемасы – махсус тикшерүне таләп итә торган өлкә.

Әдәби әсәр текстында кулланылган ялгызлык исемнәренә карата «поэтик ономастика» термины кабул ителгән. Рус ономасты Н.В.Подольская поэтик ономастиканы «матур әдәбият әсәрләрендә барлык төр ялгызлык исемнәрне, аларның барлыкка килү принципларын, стилистик һәм идеологик функцияләрен өйрәнүне, авторның дөньяга карашын чагылдыра торган ономастик термин» [1: 96], дип атый. Күренекле татар ономасты Г.Ф.Саттаров карашынча, поэтик ономастика – «матур әдәбият әсәрләренә һәм әдәби каһарманнарга исем бирү сәнгате» [2: 180].

Ялгызлык исемнәренең әдәби әсәр тукымасында тоткан урыны, аларның стилистик вазифасы тел галимнәренең игътибарын күптәннән җәлеп итте. Рус тел белемендә поэтик ономастиканың актуаль мәсьәләләре М.И.Агимбаева, М.С.Альтман, Л.И.Андреева, Н.А.Борцова, В.В.Виноградов, В.М.Голомидова, В.В.Громова, М.В.Карпенко, Н.А.Кожевникова, Н.В.Подольская, А.В.Суперанская, В.И.Супрун һ.б. галимнәрнең хезмәтләрендә чагылыш тапкан.

Рус язучылары иҗатындагы поэтонимнар төрле темага язылган диссертацияләрдә тикшерелә [3-7]. Поэтик ономастиканы монографик планда өйрәнгән В.М.Калинкин хезмәтләре зур әһәмияткә ия [4].

Г.Ф.Саттаров, шигъри ономастиканы, топоним һәм антропонимнарның матур әдәбият әсәрләрендә стилистик куллану мөмкинлекләрен өйрәнү бурычын куеп [8: 85], поэтик ономастика фәненең киләчәктә үсеш перспективаларын күрсәтә [2: 184].

Татар тел белемендә ялгызлык исемнәренең әдәби әсәрләрдә кулланылышы Казан төрки-татар ономастика мәктәбенә нигез салган, татар тел белеме тарихында беренчеләрдән булып, торак пункт атамаларын, кеше исемнәрен туплап, җыйнап, фәнни яктан тикшергән Казан университеты галиме Г.Ф.Саттаров хезмәтләрендә өйрәнелә башлый [2]. Аның «Г.Ибраһимов әсәрләрендә исем-атамалар» хезмәте ономастик категорияләрнең киң планда өйрәнелүе, язучы әсәрләре исемнәренә тел белеме күзлегеннән бәя бирелүе белән әһәмиятле. XX йөз классик язучылар әсәрләрендәге поэтик ономастика галимнең шәкертләре тарафыннан системалы тикшерелә. Хәзерге татар тел белемендә поэтик ономастика шактый нык өйрәнелгән [9-14].

Поэтик ономастиканың бер тармагы булган поэтик топонимика – әдәби әсәрләрдәге географик атамаларның матур әдәбиятта тоткан урынын, функцияләрен, барлыкка килү принципларын өйрәнә торган тармак. Топонимның эчке мәгънәсен актуальләштерү әдәби әсәрнең образлар системасын булдыруга һәм жанр хасиятләрен төгәлләштерүгә ярдәм итә. Дастан, эпос, тарихи җырларда кулланылган топонимик атамалар тагын да үзенчәлеклерәк. Алар халыкның географиясе, шуңа бәйле яшәү рәвеше, көнкүреше турында сөйли. Дастаннарда тарихи вакыйгалар сурәтләнгәндә, ялгызлык исемнәренә еш мөрәҗәгать ителә.

Халык авыз иҗаты мәдәниятнең төп компонентларыннан санала. Аларда халыкның милли тарихы, сәясәте, эстетик һәм дини-әхлакый карашлары чагылыш таба. Бу мәкаләдә иҗтимагый-тарихи, әдәби-мәдәни яктан зур кыйммәткә ия булган «Идегәй» дастанында кулланылган поэтик топонимиканың урынын һәм атамаларның семантикасын ачыклау максаты куела.

«Идегәй» дастанын фәнни яктан тикшерүдә беренче омтылышлар В.В.Радлов, П.М.Мелиоранский, А.Н.Самойлович тарафыннан ясала. Дастанны тюрколог, фольклорчы һәм тарихчы галимнәр В.М.Жирмунский, Б.Н.Путилов, Ф.Т.Вәлиев, Х.Х.Ярмөхәммәтов, Ф.И.Урманче, Ф.В.Әхмәтова, М.Х.Бакиров һ.б. өйрәнде һәм аларның фәнни хезмәтләре басылды.

«Идегәй» – феодализм дәверендә төрки ырулар, кабиләләр, халыклар арасында иҗат ителгән дастан. Аның нигезендә төрле төбәкләрдә яшәп килгән күпсанлы тарихи җырлар, риваятьләр, легендалар, экият-хикәятләр ята. Әсәр шуларның гасырлар дәвамында чарланган иҗади синтезы [15: 7]. Бу әдәби-тарихи ядкәр идея эчәлегенең нигезендә халыкның хөрлек, иминлек, бәхетле һәм тату тормыш хакындагы идеаллары ята.

«Идегәй» дастанында XIV йөзнең ахыры XV йөзнең башында Алтын Урда дәүләтенең таркалу чоры һәм Урта Азиядә Аксак Тимер дәүләтенең көчәеп китүе дәверендәге вакыйгалар тасвир ителә [16: 138]. Вакыйгалар

Идел буеннан алып Урта Азия һәм Төньяк Кавказга кадәр сузылган гаять зур географик киңлекләрдә бара. Бу вакыйгаларның үзәгендә өч тарихи шәхес тора: Алтын Урда ханы Туктамыш, Идегәй һәм Урта Азиядән төрки дәүләт хөкемдары әмир Аксак Тимер.

Фольклор һәм әдәбият белемендә дастанның төп каһарманы Идегәй шәхесен һәм образын бәяләүдә фикер төрлелеге яшәп килә. Галимнәрнең бер өлеше Алтын Урда дәүләтенең таркалуын Идегәй шәхесе белән бәйләп караса, икенчеләре исә Идегәй, бөтен властьне үз кулына алып, Алтын Урданы таркалудан янә ун ел саклый дигән караштa тора. Туктамышның уңай якларына һәм казанышларына күз йомып, яисә ике шәхесне капма-каршы куеп, Идегәйне генә уңай яктан караган өченче төрле караш та бар. Аерым галимнәр әлеге берьяклы бәяләр белән килешмиләр. Мәсәлән фольклорчы һәм тюрколог галим М.Бакиров, тарихи фактларга нигезләнеп, болай дип яза: «Бу шәхесләр Алтын Урданың бердәмлеген һәм куәтен торгызуга һәм үстерүгә икесе дә күп көч салалар һәм ниһаять, аларның үлемнәре дә әсәрдә генә түгел, тормышта да якынча бер үк төрле. Орыш-сугышларда Аксак Тимердән җиңелүе һәм социаль заказ катнашуы аркасында Туктамыш дастанда түбәнсетелебрәк тасвирланса да, асылда ул да, Идегәй кебек үк, героик-трагик шәхес. Ике хөкемдарның тормыш юлы һәм үлеме шактый охшаш булуга һич тә гаҗәпләнергә кирәкми. Урта гасырларда, бигрәк тә тынгысыз һәм гаугалы чорларда, властька дәгъва итүче төрле нәсел яки кланнар арасында гына түгел, ә бер үк ата балаларының яки кан-кардәшләрнең дә бер-берсен үтерә-үтерә хакимият башына үрмәләве, яисә шул ук юл белән көрәш мәйданыннан китүе киң таралган гадәти күренеш булган. Бу исә, үз чиратында, күп кан коелуга һәм зур корбаннарга китергән, ил һәм халык өстенә иксез-чиксез кайгы-хәсрәт һәм бәла-каза булып төшкән. «Идегәй» эпос-дастанында да без нәкъ шул хәлне күрәбез. Алтын Урданың таркалуына да асылда (әлбәттә, илдә башланган икътисади һәм демографик кризисны да кертеп) морза-бәкләрнең нәкъ менә дәүләт тәхетенә утыру яки, киресенчә, аерылып-бүленеп чыгу өчен бертуктаусыз тарткалашуы һәм, күп меңнәрчә халыкны үлем-сугыш яланына кертеп, үзара кырышу-кан коешуга мәҗбүр итүе сәбәп булган да инде. Чөнки бу дәүләтне тотып торучы бердәмлекнең һәм ил куәтенең юкка чыгуына китергән» [16: 148-149].

Әсәрдән күренгәнчә, Идегәй, Чыңгыз токымыннан чыккан Туктамышны тәхеттән куып, ил белән идарә итә башлагач, аксөяк биләрнең халыкны талавына чик куя, илне аякка бастыру өчен күп игелекле эшләр башкара. Шуңа күрә халык аны үзенең каһарманы итеп саный, гаделлеге, зирәклеге, батырлыгы өчен хөрмәт итә, ышаныч белдерә.

Идегәйнең характерына хас төп сыйфатны, аның Идел-йортка, халкына керсез мәхәббәте һәм чиксез тугрылыгы билгели. Идегәй Идел-йортка багышлап түбәндәге сүзләрне әйтә:

Әй Идел-йорт, Идел-йорт!
Идел буе имин йорт!
Атам кияү булган йорт –
Иелеп тәгъзим кылган йорт –
Анам килен булган йорт –
Иелеп сәлам биргән йорт,
Кендегемне кискән йорт,
Керем-коңым юган йорт,
Бия сауган сөтле йорт,
Кымыз эчкән котлы йорт. [17: 132].

Дастанда Идегәй *Идел* елгасы исеме белән аның буена утырган борынгы Болгар һәм Кыпчак дәүләтләрен *Идел-йорт* дип атый. *Идел* татар халкының дастаннарында, җырларында, мәкаль һәм әйтемнәрендә, бәетләрендә яратып, үз итеп, зур елга буларак сурәтләнә. *Идел* күчерелмә мәгънәдәге образга әверелеп, туган җир – Ватан, Идел-ана, туган җир кебек кеше өчен иң изге, кадерле-кыйммәтле төшенчәләрне белдерүгә хезмәт итә.

XVI йөзләрдә татарларның халык буларак оешу процессы *Идел* буйларында башлана. Борынгы чорларда *Идел* ярлары буенда зур сугышлар булган. Тарихи яктан әһәмиятле вакыйгалар, гадәттә зур сулы елга ярлары, су чыганаклары янында хәл ителгән.

Татар тел гыйлемендә *Идел* атамасының этимологиясе берничә төрле шәрехләнә.

Көнчыгыш Европадагы иң зур елганы белдерүче *Идел* атамасы язма чыганакларда беренче тапкыр б.э ның II гасырында астроном һәм географ Клавдий Птолемей хезмәтләрендә телгә алына. Европа сәяхәтчеләре сәяхәтнамәләрендә *Идел* атамасы төрле язылышта теркәлгән: *Эрдил, Ледиль, Һердил.*

Татар галимнәре фикеренчә, *Ра~Ря – Идел* елгасының бик борынгы атамасы. Фин-угыр телләре төркеменә керә торган мордва телендә Идел хәзер дә *Ра* дип йөртелә. Г.Ф.Саттаров *Ра*

~ *Ря* гидронимының асылында фин-угыр телләрендә «елга» мәгънәсен белдерә торган *ар, ари* сүзе ята дип карый [18: 28].

*Идел* – «зур елга», «елга» дигән мәгънәне белдерә. Вакытлар үтү белән, ул зур, аерым бер суның исеменә әверелгән [19: 95]. Н.Исәнбәт *ил-ат*, *ил-ат арасы, ат-ил* тәгъбирләрен болай дип аңлата: 1) Идел елгасы һәм аңа койган зур-зур елгалар өстендә борынгы һун төрекләре, соңыннан Хәзәр-Болгар, алардан соң Болгар-Кыпчак һәм Казан мәмләкәтләре яшәгән һәм ат менгән ирләр кулында идарә ителгән ил эче димәк; 2) илнең эчке үз тормышы, халык буларак яшәеше, барыш-килеше, ил-көн итеше; 3) туган ил, тугандаш халык; үз җир-суы, үз мәмләкәтенә ия булган, үз кавем-кардәш булып яшәгән төп җирле халык [20: 279]. Бу аңлатмаларны Н.Исәнбәт, тагын да ачыклап, конкрет дәлилләр белән төгәлләштереп, болай дип яза: «Борынгы Идел-Атил (ат-ил) мәмләкәте дигәнебез хәзерге Әстерхан тирәсендә булган Атил (Ат-ил) шәһәре янында диңгезгә койган Атил (Идел) елгасыннан алып хәзерге Татарстан – Мари-АССР (Мари республикасы – төзәтмә авторныкы) арасындагы Илләт (Ил-ат) елгасы тамагынача булган җирләр булып, борынгы болгар-угыз һәм фин-угырлар һәм соңыннан Казан ханлыгы яшәгән ил эче, шулай ук алар белән бәйләнештәге кәрван, су юллары һәм бу араның ат белән йөрелеше күздә тотылып әйтелгән тәгъбир. Киң мәгънәдә бу ил җирләре озак гасырлар буена Дагестаннан һәм Идел тамагыннан алып, Агыйдел, Сакмар, Кара идел (Уфимкә), Нократ (Вятка) югарыларынача, вакыты белән Ука (Ока) тамагына һәм, әлбәттә, Тобол-Төмәннәргәчә җәелгән, III-IV гасырларда һун төрекләре, Атилла (Атиллы – Иделле һәм Ат илле) хан, соңыннан болгар-хәзәр төрекләре, аннан соң болгар-кыпчак төрек-татарлары кулында идарә ителеп, дастаннарда Идел йорт дип тә йөртелгән Болгар-Кыпчак иле арасы дигән мәгънәдә таралган тәгъбир. Азербайҗан телендә дә «Элат» (яки «Елат») сүзе шулай ук кавем-кардәш, тугандаш халык дигән сүз» [20: 279].

Шулай итеп, Н.Исәнбәт *Ат-ил* мәмләкәте, *Атил* шәһәре һәм шул шәһәр янында диңгезгә койган *Атил (Идел)* елгасы атамаларының килеп чыгышын *ат-ил, ил-ат* тәгъбире белән бәйләп карый.

А.М.Малолетко *Итиль~Этил~Адиль* терминының асылында борынгы төрки телдәге *от* «үлән», «яшел үлән», «яшеллек» сүзе ята дигән фикердә тора [21: 36]. Болгар галимнәре төрки халыкларның зур суларны, шул исәптән Днепр, Буг, Дунай елгаларын да *Этил~Итил* дип атап йөртүләрен ачыклаганнар [19: 97]. Узган гасырның 30 елларында хәзәр телен һәм тарихын өйрәнгән А.Р.Зифельдт-Симумяги, элек Дон елгасының *Эстел~Этель* дип йөртелүенә игътибар итә. Ул *Итиль* гидронимы – «су» (самоедча *иту* «су») + «су» (вогульча *эл* «су») яки *елга+елга* мәгънәсенә ия булган гибрид атама булуын раслый. Г.Ф.Саттаров бу карашны дөреслеккә туры килә дип саный һәм аны яклый [18: 32]. Болгар бабаларыбызда Идел елгасы буенда күченеп йөргәндә туган балаларга *Идел* компонентлы исемнәр кушу гадәте булган: *Идел, Иделбай, Иделбәк, Иделле, Иделморат, Иделхан, Иделбикә, Иделсылу* һ.б. [22: 157]. *Идел* компоненты Казан татарларының исемнәрендә *Иделбаев, Иделханов, Иделлиев* кебек фамилияләрендә сакланып калган.

IX–XIII гасырларда Идел һәм Кама елгалары төбәгендә, бар яктан да алга киткән, рус кенәзлекләре, төньяк халыклары, Хәзәр иле, Урта Азия, Кавказ, Византия, Иран, Гарәп хәлифәлеге белән сәяси, сәүдә, мәдәни мөнәсәбәтләр урнаштырып көн күргән Идел-Чулман болгарлары дәүләте яшәгән. Бу дәүләтнең көнчыгыш чикләре *Җаек* елгасы буйлап үткән. *Идел* һәм *Җаек* топонимнары татар халкы дастаннарында, тарихи җырларында һ.б. авыз иҗатында һәрдаим янәшә кулланыла. Мәсәлән:

Идел-Җаек арасы
Йолкы белән тулган йорт,
Казан – Болгар арасы
Кала белән тулган йорт [17: 132].

Төрки-татарлар утрак тормыш алып, шәһәрләрдә яшәгәнгә күрә, *Казан* һәм *Болгар* арасында күп шәһәрләр төзелгән. Халык тарихын, көнкүреш үзенчәлеген һәм акылын гәүдәләндергән мәкаль һәм әйтемнәрдә алар берегеп, сакланып калган: *Җаек – энесе, Идел – агасы, икесе ил агасы. Җаекның җаен бел, Иделнең иңен бел. Идел – йортның ишеге, Җаек – йортның түре.*

*Җаек* – Россия һәм Казахстан җирләре аша үтеп, Каспий диңгезенә коя. Бу елга татар халкы тарихы белән бәйләнгән. Шактый озак вакытлар *Җаек* һәм *Идел* арасы күчмә нугайлар җире булып исәпләнгән. Ә.Әфләтунов типтәрләр телендә *җай* сүзенең «елга»ны аңлатуын, *Җаек* һәм *Зәй* атамалары нигезендә

*җай* «елга» термины ятуын күрсәтә [23: 67]. Г.Ф.Саттаров, Ә.Әфләтунов фикерен куәтләп, борынгы төрки кабиләләр телендә «елга», «елгачык» мәгънәсен белдергән *чай ~ сай ~ тай ~ шай ~ зай ~ зәй ~ най ~ йай* сүзләренең җиде төрле вариантын ачыклап, *ч~с~т~ш~з~н~й* тартык авазларының тарихи тәңгәллеген раслый торган факт булуын билгели. Татарстандагы Зәй, Чайшур, Каратай, Бакалтай атамаларының килеп чыгышын да әлеге карашка таянып нигезли. Г.Ф.Саттаров Урта Идел-Урал буе территориясендә, б.э. ның III – XVII гасырлары аралыгында сөйләшләре бер-берсеннән шактый аерылган кардәш төрки кабиләләр яшәгәннәр һәм аларның буыннары казан татарларының тарихи-этник процессында катнашканнар дигән нәтиҗә ясый [24: 72]. Бу тартыкларның тәңгәллекләре татар теле диалектларында әлеге көнгә кадәр сакланып калган. Академик М.З.Зәкиев тә *җай ~ чай ~ зәй ~ зөя* сүзләрен борынгы төрки телдәге «елга» мәгънәсен бирә торган сүзнең диалекталь вариантлары дип карый [25: 88]. Кайбер төрки телләрдә *чай, сай, тай, җай* терминнары хәзер дә «елга» мәгънәсендә кулланыла [26: 199].

«Идегәй» дастанында *Казан суы* һәм *Казан шәһәре* атамалары кабатланып киләләр.

Болгардаен калам бар,
Болгар йортын алырмын,
Болгарда да тынмасам,
Куе урманның төбендә
Куерып аккан Ашыт су,
Кара урманым төбендә
Каралып аккан Казан суы,
Казан суның буенда
Капкасы биек таш Казан
Ул каламны алырмын [17: 132].

*Казан шәһәре* исеменең килеп чыгышы, ягъни *«Казан»* топонимының этимологиясен ачыклауның тарихи-мәдәни һәм тарихи-лингвистик әһәмияте зур.

*Казан* – Татарстан Республикасының башкаласы – илебезнең борынгы һәм бай тарихлы шәһәрләренең берсе. *Казан шәһәре* X-XI йөзләрдә – Идел буе Болгарының төньяк төбәгендә сәүдә итү һәм дошман һөҗүменнән саклану пункты, XIII йөздән XV йөзнең 30 еллары ахырына кадәр бәклек үзәге, 1438 елдан Казан ханлыгы мәркәзе була. 1552 елда шәһәр Рус дәүләте тарафыннан яулап алына. 1708-1920 елларда – губерна үзәге, 1920 елдан Татарстан автономияле республика, ә 1990 елдан Татарстан Республикасы башкаласы. Ул XIX йөздән Россиянең зур икътисади-сәяси, сәүдә, мәдәни һәм фәнни үзәгенә әверелә.

*Казан шәһәре Казан елгасының Иделгә* коя торган тамагына, Европадагы иң зур елга – *Идел* елгасының урта агымында сулъяк ярга урнашкан. Шәһәрне табигый су системасын тәшкил иткән *Казан елгасы, Болак суы һәм Кабан күлләре* өч өлешкә аера.

Казан 425,2 км$^2$ мәйдан били, җиде административ районга бүленә.

Тарихчы һәм археологлар *Казан Кремле* территориясендә X гасырда чокылган гарәп дирһәме һәм чех монеталары табалар. Аларның яңа тикшеренүләре нәтиҗәсендә, Казан шәһәренә X гасырда нигез салынган дигән караш расланды. Казанның дөнья цивилизациясе үсешенә керткән зур өлешен, Россиянең сәяси, икътисади, фәнни һәм мәдәни үзәге булуын исәпкә алып, 2005 елда Казан шәһәренең 1000 еллыгы рәсми төстә билгеләп үтелде [27: 8].

*Казан* шәһәренең атамасы әдәби әсәрләрдә, тарихи әсәрләрдә, җырларда, дастан-эпосларда бик еш кулланыла. *Казан* топонимы Кавказда, Болгариядә, Украинада, Башкортстанда, Көнбатыш Себердә, Иранда, Төркиядә бар.

*Казан* сүзенең килеп чыгышы һәм мәгънәсе турында күптөрле карашлар яши. Бу сүзнең күпмәгънәлелеге яки аның омоним сүзләр оясын тәшкил итүе шәһәр атамасының килеп чыгышын төрлечә аңлатуга китергән. Халык этимологиясе дә, топо-легендалар да, галимнәр фикерләре дә шушы сүзнең теге яки бу мәгънәсенә нигезләнә. Шуларның берничәсенә тукталып үтик.

Борынгы топонимик легендада Болгар ханы Габдулла улы Алтынбәкнең хезмәтчесе, су алганда, алтын казанын елгага төшереп җибәрүе, шуннан бу елгага Казан исеме бирелүе һәм әлеге елга янына салынган шәһәрнең дә Казан дип йөртелә башлавы бәян ителә.

В.В.Радлов, М.Г.Худяков, А.А.Сергеев кебек тикшерүчеләр *Казан* атамасы шәһәр салынган урынның казан шикелле тирән чокырлы булуына нигеләнгән дигән караште торалар.

1767 елда П.И.Рычков Казан елгасының исемен аның төбенең казан сыман чокырлы булуы белән бәйләп аңлата [28: 102]. Бу караш XIX йөздә М.Н.Пенигин, профессор М.С.Шпилевский, XX йөздә Е.Г.Бушканецлар тарафыннан хуплана. П.И.Рычковның «Иске

Казанга Алтын Урданың Чыгтай улусында ханлык иткән Казан-Солтан хан яки Казан исемле башка бер татар принцы нигез салган булуы да ихтимал» [28: 103] дигән фаразын XIX йөзнең күп кенә галимнәре яклап чыга.

Тарихчы Һ.В.Йосыпов карашынча, «*Казан* топонимы *казан* этнонимыннан килеп чыккан. Элек татарларда «Казантау җыены» булган, чөнки җыен ыруг-кабилә атамасын йөрткән. *Казан* атамасы Кубаньда, Украинаның көньягында, Каспий диңгезенең төньяк-көнбатыш яры буйларында күп таралган. Төркиянең төньяк-көнчыгыш территориясендә *Казан* исемле шәһәр бар һәм боларның килеп чыгышы төрекмәннәрнең *казан-салор* кабиләсе исеме белән бәйле. Кара диңгез һәм Азов буе далаларына казан кабиләсенең Төрекмәнстаннан килүе, аннан болгар кабиләләре белән бергә, Урта Идел буена күтәрелеп, соңыннан Казан кенәзлеге халкының нигезен тәшкил иткән» дигән караштa тора [29: 229-230].

Башкорт топонимисты А.А.Камалов җирле географик номенклатура терминнарының семантикасын исәпкә алуны мөһим дип саный. Шушы яссылыкта *каран* «елганың катмый торган, тирән урыны» һәм *казан* «казанлык, чокыр» топонимнары арасындагы семантик бәйләнешне танып, беренче топонимның болгар чыгышлы, икенчесенең кыпчак чыгышлы булуын искәртә [30: 206-207].

Тарихчы А.Х.Халиков *qas, qasiq* сүзләренең борынгы төрки телдә «кабык», «агач кайрысы», «тышча» мәгънәсендә кулланылуларыннан чыгып, *кас* сүзе татар телендә нечкә әйтелеш алып, *кәс* мәгънәсенә ия булган һәм болгар чорында *каз* сүзе кабыкны гына аңлатмыйча, «чик», «кырый» мәгънәләрен дә белдергән, ди. *Каз* сүзенең тагын да борынгырак формасы *каш* рәвешле булган булса кирәк, чөнки борынгы төрки телдә *каш* «кырый, яр, чик» мәгънәсендә килә. Галим, шушы аңлатмаларга таянып, *Казан* исеме борынгы болгарлар тарафыннан бирелгән һәм ул *чик* «граница» дигән мәгънә аңлаткан, ә *Казан* сүзе ике өлештән торып, *-ан* борынгы төрки телдә «урын», «өлкә», «территория» төшенчәсен белдерә торган кушымча булган дигән нәтиҗәгә килә [31: 14].

Татар ономасты Г.Ф.Саттаров исә, югарыда китерелгән фаразларны кире кагып, Казан атамасының мәгънәсен түбәндәгечә аңлата: *каз* – сүзнең тамыры һәм *-ан* үткән заман сыйфат фигыль формасы. Бу сүзнең беренче формасы *казган* рәвешле булган. *Kaz* сүзенең борынгы төрки телдә «рыть, копать, выкапывать» [32: 439] мәгънәсендә кулланылуы мәгълүм һәм *Казан* елгасының исеме, «җирне казыган елга», «җирне казып-уеп агучы елга» мәгънәсен белдергән хәлдә, иң элек *Казыган елга* > *Казган елга* > *Казан елга* рәвешле әйтелеп йөреп, тора-бара елга гидрографик номенклатур терминының төшеп калуы нәтиҗәсендә *Казан* әйтелешен алган. Шушы лексик-семантик ысул белән төрки халыклар элек һәм хәзер дә яши торган территорияләрдә *Казан* дигән елгаларның исемнәре барлыкка килгән. Урта Иделгә коючы *Казан елгасы* исеменә нисбәтле рәвештә болгар бабаларыбыз тарафыннан аның буена салынган кала да *Казан каласы* > *Казан* дип аталган дигән нәтиҗәгә килә [24: 53]. Галим элегрәк язылган «Происхождение названия Казань» хезмәтендә Казан борынгы төрки *каз кабиләсе* исеменә нисбәтле рәвештә барлыкка килгән һәм «каз кабиләсе елгасы», «буйларында каз кабиләсе яши торган елга» төшенчәсен белдерә дип язган иде [33]. Бу караш кайбер галимнәр тарафыннан кире кагылды, ә кайберләре аны хуплады.

М.З.Зәкиев XX гасырның 70 елларында әйтелгән Һ.В.Йосыпов фикеренә кушыла һәм *Казан* атамасын этноним белән бәйләп карый [34: 251-252]. Казан атамасының киң регионнарда таралуына игътибар итеп, казан этимологиясен *кусан ~ кушан: ку* «аксыл сары» *сөн (сан ~ зан ~ шан)*, ягъни *кусан ~ касан ~ казан* этнонимы «аксыл сары сөннәр» дигән мәгънәне аңлата дип ассызыклый.

Безнең карашыбызча, шәһәр атамасы *Казан елгасы* белән бәйле булып, *Казан шәһәре* исеме икенчел, ә *Казан елгасы* – беренчел һәм бу атаманың төрки хәзәр кабиләсе этнонимы белән бәйләнеше бар.

Шулай итеп, топонимик берәмлекләр әсәр тукымасында билгеле бер әдәби-эстетик функция башкаралар һәм текстта аларның топонимик мәгънәләре әһәмиятле роль уйный. Поэтик топонимнар, гадәти топонимнардан аермалы буларак, реаль тормыш картиналарын сурәтләү һәм характерлау функцияләрен үтиләр, ягъни алар ниндидер географик объектны атау белән генә чикләнмичә, яңгырашы һәм этимологиясенә бәйле рәвештә өстәмә стилистик мәгънә белдерә башлыйлар.

Алтын Урданың Идегәй йогынтысында булган кыпчак телле олысларында җирле риваять-легендалар нигезендә иҗат ителгән «Идегәй» дастанын филологик планда өйрәнү

бик мөһим. Анда иҗтимагый-милли тарих белән бәйле вакыйгаларны сурәтләгәндә, ялгызлык атамаларына еш мөрәҗәгать ителә һәм бу поэтик топонимнарны, лингвистик, поэтик аспектта якын килеп, комплекслы өйрәнү актуаль һәм кызыклы мәсьәләләрнең берсе булып тора. Дастандагы Казан, Идел, Җаек һ.б. поэтик топонимнары татар халкының күп еллар буена тупланган бай сүзлек хәзинәсенең бер өлеше булып, алар төбәкнең табигате, халыкның теле, тормыш көнкүреше, тарихы, этногенезы турында кыйммәтле мәгълүматлар бирә.

Әдәби әсәрләрдә, тарихи ядкәрләрдә кулланылган поэтик топонимика татар халкының рухи, әдәби-мәдәни тормышында хәзер дә зур роль уйный.

**Әдәбият**


1. *Подольская Н.В.* Словарь руской ономастической терминологии. 2-е изд. М.: Наука, 1988. 365 с.
2. *Саттаров Г.Ф.* Г.Ибраһимов әсәрләрендә исем-атамалар // Казан утлары, 1993. № 6. Б. 180-184.
3. *Немировская А.Ф.* Ономастическое пространство в художественном тексте: На материале романа О.Т. Гончара «Твоя звезда»: Автореф. дисс. … канд. филол. наук. Киев, 1989. 20 с.;
4. *Калинкин В.М.* Поэтика собственных имен в произведениях романтического направления: Автореф. дисс. … канд. филол. наук. Донецк, 1987 16 с.;
5. *Бардакова В.В.* Специфика литературной ономастики детской художественной прозы: Автореф. дисс. … канд. филол. наук. Волгоград, 2000. 22 с.;
6. *Бондаренко Т.А.* Антропонимия романа Ф.М.Достоевского «Братья Карамазовы»: система, структура, функции: Автореф. дисс. … канд. филол. наук. Тюмень, 2006. 23 с.;
7. *Курс К.Ю.* Имена собственные в поэзии М.В. Исаковского: структурно-семантический и функциональный анализ: Автореф. дисс. … канд. филол. наук. Смоленск, 2013. 26 с.
8. *Саттаров Г.Ф* Этапы развития и очередные задачи татарской ономастики. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1970. 88 с.
9. *Гаррапова Р.Х.* Поэтическая ономастика прозы Мухаммата Магдеева: Автореф. дисс. … канд. филол. наук. Казань, 2000. 24 с.;
10. *Биктимерова А.Р.* Лингвистическая и ономастическая поэтика татарских народных песен: Автореф. дисс. … канд. филол. наук. Казань, 2002. 23 с.;
11. *Арсланова С.С.* Лексико-семантические, стилистические особенности и поэтическая ономастика либретто Мусы Джалиля «Алтынчэч» и «Илдар»: Автореф. дисс. … канд. филол. наук. Казань, 2004. 24 с.;
12. *Гарипова-Хасаншина В.М.* Поэтическая ономастика прозы Гумера Баширова: Автореф. дисс. … канд. филол. наук. Казань, 2004. 24 с.;
13. *Зиннатуллина Г.Х.* Поэтическая ономастика прозы Амирхана Еники: Автореф. дисс. … канд. филол. наук. Казань, 2005. 25 с.;
14. *Нуруллина Ф.Ф.* Поэтическая ономастика драматургии Туфана Миннуллина: Автореф. дисс. … канд. филол. наук. Казань, 2011. 23 с.
15. *Надиров И.* «Идегәй» дастаны // Идегәй. Татар халык дастаны / төз.-ред. Г.Гыйльманов, Х.Әюпов. Казан: Тат. кит. нәшр., 1988. Б. 5-10.
16. *Бакиров М.* «Идегәй» дастанына яңа караш // Казан утлары, 2008. № 8. Б. 138-150.
17. Идегәй. Татар халык дастаны / төз.-ред. Г.Гыйльманов, Х.Әюпов. Казан: Тат. кит. нәшр., 1988. 254 б.
18. *Саттаров Г.Ф.* Татар топонимиясе. Казан: Казан ун-ты нәшр., 1998. 438 б.
19. *Гарипова Ф.Г.* Исемнәрдә – ил тарихы. Казан: Татар. кит. нәшр., 1994. 264 б.
20. *Исәнбәт Н.* Татар теленең фразеологик сүзлеге. Ике томда. I том. Казан: Тат. кит. нәшр., 1989. 495 б.
21. *Малолетко А.М.* Палеотопонимика. Томск: Изд-во Томского ун-та, 1992. 262 с.
22. *Саттаров Г.Ф.* Татар антропонимикасы. Казан: Казан ун-ты нәшр., 1990. 278 б.
23. *Әфләтунов Ә.* БАССРның көнбатыш, көньяк-көнбатыш өлешендә яшәүче татарлар сөйләшенең тел үзенчәлекләре: Дис. … филол. фән. канд. Казан, 1960. 186 б.
24. *Саттаров Г.Ф.* Мәктәптә туган як ономастикасы. Казан: Тат. кит. нәшр., 1984. 208 б.
25. *Зәкиев М.З.* Татар халкы теленең барлыкка килүе. Казан: Тат. кит. нәшр., 1977. 208 б.
26. *Хадиева Г.К.* Географические термины в исторической ойконимии Республики Татарстан О (по материалам писцовых книг XVI–XVII веков) // Средневековые тюрко-татарские государства. Сборник статей. Вып. 6. Материалы международной научной конференции «Средневековые тюрко-татарские государства и их соседи в системе международных отношений (XV–XVIII вв.)» (г.Казань, 14–15 марта 2014 г.). Казань: Институт истории им.Ш.Марджани АН РТ, 2014. С. 199-202.
27. *Хадиева Г.К.* Ойконимы периода Казанского ханства. Казань, 2004. 196 с.
28. *Рычков П.И.* Опыт казанской истории древних и средних времен. Спб., 1767. 262 с.
29. *Юсупов Г.В.* Булгаро-татарская эпиграфика и топонимика как источник исследования этногенеза казанских татар // Вопросы этногенеза тюркоязычных народов Среднего Поволжья. Казань, 1971. С. 220-232.

30. *Камалов А.А.* Башкортстан топонимиясен өйрәнүнең кайбер мәсьәләләре // Ономастика Поволжья. Уфа, 1973. С. 206-207.
31. *Халиков А.Х.* О времени, месте возникновения и названия города Казани // Из истории культуры и быта татарского народа и его предков. Казань, 1976. С. 3-19.
32. ДТС – Древнетюркский словарь. Л.: Наука. 1969. 676 с.
33. *Саттаров Г.Ф.* Происхождение названия Казань // Ономастика Поволжья. Горький, 1971. С. 155-165.
34. *Зәкиев М.З.* Төрки-татар этногенезы. М: Инсан, 1998. 624 б.

# ПОЭТИЧЕСКАЯ ТОПОНИМИЯ ДАСТАНА «ИДЕГЕЙ»

**Гульфия Камиловна Хадиева,**
Казанский федеральный университет,
Россия, 420008, г. Казань, ул. Кремлевская, д.18,
gul-khadieva@yandex.ru.

**Ибрагим Акыш,**
Стамбульский университет,
Турция, 34452, г. Стамбул, Баязит Фатих, ул. Бесим Умер Паша, д.11,
akisibrahim33@gmail.com.

Во второй половине XX века в татарском языкознании начинается углубленное изучение ономастики за счет введения в научный оборот данных из других языков. Весьма результативными оказались достижения татарской топонимики, изучающей географические наименования. В дастанах при описании исторических событий часто употребляются имена собственные. В данной статье исследуется поэтическая топонимия историко-эпического, стихотворного дастана татарского народа «Идегей», раскрываются художественно-эстетические особенности и семантика топонимических единиц. Дастан «Идегей» признан учеными как произведение, имеющее общественно-историческую и художественно-культурную ценность. В статье излагается краткая история наименований *Идел (Волга), Җаек (Урал), Казань*, употребленных в данном произведении.

**Ключевые слова:** татарский язык, поэтическая ономастика, поэтическая топонимия, этимология, дастан «Идегей», Идел, Җаек (Урал), Казань.